Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы Карары

26 август 2019 ел

№ 107

**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендәге 38 номерлы карары белән расланган Әтнә муниципаль районы «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы «Мәҗбүри иминият системасында индивидуаль (персонификацияләнгән ) исәпкә алу турында «Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 2012 елның 20 июнендәге 36 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында» Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 15 статьяның 15.3 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) индивидуаль (персонификацияләнгән ) исәпкә алу системасында, шул исәптән электрон документ формасында теркәлүне раслый торган документ;»

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча ) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында : (pravo.tatarstan.ru веб –адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Түбән Бәрәскә авыл башлыгы А.В.Фатыйхова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН АТНИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОГРН 1021606155405
Совет Нижнеберескинского сельского Поселения
ИНН 1610000476 КПП 161001001